Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№8 (101)

20 март 2014 ел

# Бездә чын яз!



Влад Михневский фотосы

Әгәр яз «Студентлар язы» фестивале белән башланса, җәй эссе һәм рәхәт, көз бик уңышлы булачак, ә кышын кары да вакытында явып, бураны да вакытында дулаячак, дигән ышану бар безнең уку йортында. Алай гына да түгел, студентлар барлык зачет-имтиханнарын да гел яхшы билгеләргә генә тапшырачак. Университетыбызда март башында старт алган фестиваль бүген Алабуга институтында тәмамланачак. Иң матур, иң яхшы, иң шәп номерларны без 23 апрель көнне УНИКС концертлар залында гөрләячәк «Студентлар язы» фестиваленең гала-концертында күрә алачакбыз.

## Вакыйгалар эзеннән

Күптән түгел Казахстанның Актүбә дәүләт төбәкара университеты һәм КФУның ФһМБИ катнашында **«ФИЛОЛОГИЯНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ»** дигән темага багышланган онлайн-видеоконференция уздырылды. Чарада институтның Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары һәм магистрантлары катнашты. Актүбә университеты магистрантлары казах халкының тарихы, әдәби әсәрләрне дөрес тәрҗемә итү, фольклорга багышланган проблемаларны күтәрделәр. Безнең магистрантларның чыгышларында исә күбрәк татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасына караган мәсьәләләр яктыртылды.

• • • •

13-16 **МАРТ** көннәрендә Мәскәүдә яшүсмерләр арасында үткәрелгән **ПАУЭРЛИФТИНГ** (жим лежа) буенча **РОССИЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ** уздырылды. Анда Россия һәм дөнья беренчелекләрендә кат-кат җиңү яулаган Алабуга институты студенты Анна Филимонова да катнашып, беренче урынга лаек дип табылды. Әлеге җиңүе Аннага 2014 елда Даниядә узачак Дөнья Беренчелегендә катнашачак РФ җыелма командасына керүгә юл ачты.

• • • •

**17 МАРТТА** ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше, математиклар көненә әзерлек, якын киләчәктә уку йортында узачак чаралар турында сөйләде. Конкурентлыкка сәләтлелекне арттыруның комплекслы мониторингы белән Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** таныштырды. Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының телетапшыру һәм тележитештерү кафедрасы җитәкчесе **Р.ДАУТОВА** һәм Медиа-Үзәк директоры **И.КӘРИМОВ** кафедра базасында «Яңа Гасыр» телеканалы директоры, танылган журналист И.Әминовның иҗади лабораториясен ачу тәкъдиме белән чыктылар. Биредә практикага зур игътибар биреләчәк, аларны И.Әминов үзе, телеканалның башка журналистлары алып барачак. Лабораториянең максаты – тележурналистларны әзерләүнең сыйфатын арттыру. «Экологик инновацияләр» фәнни-укыту лабораториясе эшчәнлеге белән Экология һәм география институты директоры **С.СЕЛИВАНОВСКАЯ** таныштырды. Кабул итү кампаниясенең уңышлары турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** җиткерде. Аның сүзләренчә, Үзбәкстан һәм Казахстанда уздырылган профориентацион эшләрдән соң, КФУга өч йөзләп укучы укырга, утызлап студент магистратурага керергә теләк белдергән.

• • • •

Шул ук көнне ректор **И.ГАФУРОВ** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының структур бүлекчәсе булган **КАЗАН ХАЛЫКАРА ЛИНГВИСТИК ҮЗӘГЕ** белән **ТАНЫШТЫ**. Бүгенге көндә үзәкнең 8 аудиториясе һәм 4 офисында заманча ремонт ясалган. Алар интерактив такталар, ноутбук, планшетлар, яңа укыту-методик комплекслары белән җиһазландырылган.

• • • •

**17 МАРТТА КФУ** һәм **АЕГЕН УНИВЕРСИТЕТЫ** (Греция) арасында **ХЕЗМӘТТӘШЛЕК** булдыру ниятләре турындагы **ПРОТОКОЛГА КУЛ КУЕЛДЫ**. Очрашу дәвамында фәнни-тикшерену эшләре һәм белем бирү программалары өлкәсендә хезмәттәшлекне һәм үзара бәйләнешне киңәйтү буенча приоритетлы чаралар билгеләнде.

**18 МАРТ** көнне КФУда Халыкара **КЫЗЫЛ КРЕСТ КОМИТЕТЫ ВӘКИЛЛӘРЕ** комитетның 150 еллыгына багышланган **ОЧРАШУ УЗДЫРДЫ**. Чара комитетның тулы эшчәнлеген чагылдырган фильм белән башланып китте. Тагын да тулырак мәгълүматны белгечләр Лиз Харрис һәм Татьяна Жоливе бирде. Комитетта эшләргә теләүче студентлар, 25 яшь тулгач, резюме җибәреп, эшкә урнаша ала.

• • • •

**КФУ ТУРЫНДА** иң яхшы презентациягә **КОНКУРС** башланды. Анда уку йортыбызның студентлары, лицей укучылары, укытучылар катнаша ала. Моның өчен уку йорты турында рус яки инглиз телләрендә видеоролик яисә Power Point форматында эшләнгән презентацияне 13 апрельгә кадәр ***marketing@kpfu.ru*** адресына җибәрергә кирәк. Җиңүчеләрне бик зур бүләкләр көтә.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Халыкара мөнәсәбәтләр



# Мирас сакчылары

**Уку йортыбыз галимнәре республика, ил күләмендә генә түгел, ә халыкара масштабта уза торган чараларда да актив катнашып, уку йортыбыз данын күтәрә.**

Университетыбыз вәкиле, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты профессоры Альберт Борһанов та шундый актив галимнәребезнең берсе. 11-14 март көннәрендә Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең Археология һәм этнография институты (Ашхабад шәһәре) һәм «Аваза» Милли туристлар зонасында (Төрекмәнбаш шәһәре) үткәрелгән «Борынгы һәм урта гасыр Евразия мәдәниятләре системасында көньяк-көнчыгыш Төрекмәнстан мирасы» исемле Халыкара фәнни конференциядән ул да читтә калмады. Алай гына түгел, ул бу чараны оештыруда катнашучыларның берсе дә.

Җыенның географиясе киң: анда Америка, Европа, Азия һәм Африканың 36 иленнән академия һәм вузларның әре фәнни-тикшеренү үзәк вәкилләре катнашты. Әлеге чара үз өлкәләрендә танылган галимнәр: көнчыгышны өйрәнүчеләр, тарихчы, этнограф, археолог, филолог һ.б.ны бергә туплап, зур масштаблы конференциягә әверелде. Килгән кунаклар тарихи-мәдәни мирас, чыганаклар, тарихны өйрәнү һәм саклап калу, көньяк-көнчыгыш Төрекмәнстанның борынгы һәм урта гасыр матди һәм рухи мәдәнияте мәсьәләләре турында фикер алыштылар, чыгыш ясадылар һәм булган проблемаларның чишелү юлларын эзләделәр.

А.Борһановның чыгышы исә көньяк-көнчыгыш Төрекмәнстанның (Койтендагс төбәге кысаларында) тарихын һәм археологик һәйкәлләрен өйрәнү перспективалары мәсьәләләре, тикшерү нәтиҗәләренә багышланган иде. КФУ профессоры, конференция нәтиҗәсе итеп уздырылган түгәрәк өстәлдә дә катнашып, Койтендагс төбәге һәм Көнчыгыш Төрекмәнстанны алга таба үстерү буенча Дәүләт программасы проектын тәкъдим итте.



*Ашхабадның милли музеенда археологик табышларга багышланган экспозиция ачылды. Анда Төрекмәнстанның борынгы, антик һәм урта гасыр чоры археологиясенә караган сирәк очрый торган материаллар тупланган. Алар белән бергә, биредә Урта Азия һәм Төрекмәнстанның борынгы тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән археологларга багышланган өч фотостенд та бар. 37 бөек галим арасында Көнчыгыш Төрекмәнстанны өйрәнгән профессор А.Борһановның да булуы – университетыбыз өчен зур горурлык!*

• Син+Мин=БЕЗ!

# Президент сайланды!

**19 март көнне УНИКСта Татарстан Республикасы Студентлар Лигасы конференциясе булып узды. Чарада оешманың V Президентын да сайладылар.**

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Конференциядә ТР премьер-министры **Илдар Халиков**, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рафис Борһанов, КФУ Президенты **Мәгъсүм Сәлахов**, Россия студентлар оешмалары Ассоциациясе Президенты **Вячеслав Адерихин** катнашты. Лиганың хәзерге Президенты Тимур Сөләйманов оешманы 2010 елның 15 мартыннан җитәкли. Ул җитәкчелек иткән 4 ел эчендә Лига оештырган проект һәм программаларда катнашучыларның саны бермә-бер арткан – 30 мең студентка кадәр җиткән. Студентлар Лигасының соңгы еллардагы үсеш үзенчәлеген аның социаль юнәлеше билгели. Оешманың 2010-2014 еллардагы эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында сөйләгәндә, **Тимур Сөләйманов** кыскача гына оешманың кылган гамәлләре белән таныштырды. Лобачевский исемендәге конференциягә яндан торгызу, «ВУЗ көне», «Ел студенты» конкурсының сыйфатын һәм эчтәлеген үзгәртү, «Транспорт гранты» проектын тормышка ашыру, ЮНЕСКОның проектлы идарә итү халыкара мәктәбен оештыру, чит ил студентлары белән эшли торган комитетка нигез салу – болар Лига эшләгән эшләрнең кайберләре генә.

ТР премьер-министры И.Халиков, үз чиратында, куйган хезмәте һәм ирешкән уңышлары өчен Т.Сөләймановка рәхмәтен белдерде, Студентлар Лигасын 18 яшьлек туган көне белән тәбрик итте. И.Халиков оешма тормышка ашырган чара-проектларның мөһимлеге хакында да сүз йөртте. «Сезгә ярдәм итү – Республикабызның киләчәген формалаштыручы юнәлеш», – дип белдерде ул.

Быел Студентлар Лигасы Президентын сайлау яңа форматта – яшерен тавыш бирү юлы белән уздырылды. Президентлыкка кандидатларның берсе – безнең



университет студенты Илдар Хөҗҗәтов. Икътисад һәм финанслар институтының 5 курсында белем алучы Илдарны Татарстан Республикасының «Ел студенты - 2013» буларак та беләбез. Икенче кандидат Элькин Искәндәров Казан дәүләт технология университетының 5 курсында укый. Ул Студентлар Лигасының физик тәрбия, спорт һәм туризм буенча Президент урынбасары буларак билгеле. Сайлауга кадәр бер ай дәвамында кандидатлар Студентлар Лигасы әгъзаларының тавышлары өчен көрәште: республикабызның төрле югары уку йортлары студентлары белән очрашулар, фикер алышу, бәхәскә корылган әңгәмәләр уздырды.

Конференциядә дә Илдар белән Элькин программаларын тәкъдир иттеләр. Президент булган очракта, кайсы юнәлешләрдә эшләячәкләре турында тәфсилләбрәк сөйләделәр. Илдар чыгарылыш курс студентлары белән эшләү механизмын камилләштерү, Студентлар Лигасы вәкилләрен ТР министрлыклары һәм ведомстволарына кертү, муниципаль район активлары белән эшне җайга салу, сәламәтлеге чикле студентлар белән эшләүне төп бурычлары дип билгеләде.

Элькин Студентлар Лигасы тарафыннан тормышка ашырыла торган проектларны тагын да уңышлырак итү юлларын эзләргә ниятләвен белдерде һәм сайлауда катнашачак һәркемне социаль җаваплылыкка чакырды.

Тавышларны санау алдыгы 4 елга Студентлар Лигасының Президенты итеп Элькин Искәндәровның билгеләнүен күрсәтте. 812 сайлаучының 415е нәкъ менә аның өчен тавыш бирде.



Влад Михневский фотосы

• Эшлекле сөйләшү

# Яхшылар рәтендә

**Алинә САДЫЙКОВА**

**19 март көнне Юридик факультет коллективы университет җитәкчелеге белән очрашты. Утырышта әлеге структур бүлекнең 2013 ел нәтиҗәләре һәм 2014 елга планнары турында сөйләштеләр. Аны юридик факультет деканы Илдар Тарханов алып барды.**



Чарада Казан университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры **Р.Минзарипов**, факультет вәкилләре, галимнәре, укытучылары һәм студентлары катнашты.

Юридик факультет – гуманитар профильгә караган структура. Ул Россиянең өч юридик мәктәпләренең берсе санала. Бүгенге көндә анда сигез кафедра эшли һәм 3362 студент белем ала. Шуларның кырык тугызы – чит ил вәкилләре. Аларны тагын да күбрәк җәлеп итү йөзеннән, чит ил студентлары өчен, факультетта чит ил законнарына йөз тоткан махсус программа эшләнә башлаган.

Магистратурада исә барысы 59 шәкерт укый. И.Тарханов фикеренчә, бу сан алдагы елларда әле тагын да үсәчәк, чөнки 6 профильле әзерлек курсларының өчесе халыкара дәрәҗәдә. Ә менә икенче югары белем алучылар саны кимүгә таба бара икән.

Юл картасы мәгълүматларына караганда, факультетның күрсәткечләре яхшы. Мисал өчен, юридик факультет укытучыларының Scopus һәм Web of Science базаларында басылган мәкаләләр саны куелган планга караганда да күбрәк. Университетның үсеш программасы рейтингында бу структура 5 урында тора.

И.Тарханов үзләрен борчыган мәсьәләләр хакында да сүз кузгатты: «Безнең фикеребезчә, уку программасын бакалавриат һәм магистратурага күчерү бик зур хата булды. Магистратурага һәр студент та бармый. Ә юрист әзерләү өчен, 4 ел гына бик аз», – диде. Шуңа күрә, факультет җитәкчеләре тулы хокуклы юрист әзерли торган 5 еллык программа булдыру ниятләре белән яна.

Гомумән, университетыбыз юристларының яңа идеяләре күп. Якын киләчәктә алар өстенлекле юнәлешләрне гамәлгә ашыру программасын һәм студентлар советы структурасын оештырырга уйлыйлар.

Р.Минзарипов юридик факультетның планнарын хуплады һәм университет тарафыннан ярдәм итү мөмкинлеге булу турында әйтте. «Юрфак студентлары – яхшылар рәтендә, сезнең мөхитегез уңышлы һәм тиешле дәрәҗәдә. Шуңа күрә университет эшчәнлегендә барган үзгәрешләргә уңай йогынты ясарсыз дип өметләнәм!» – диде ул.

Утырыш азагында факультет вәкилләре үзләрен борчыган сорауларга да җавап ала алдылар. И.Тарханов исә хезмәткәрләрен кирәгеннән артык тыйнаклыктан арынырга һәм булган мөмкинлекләрдән максималь рәвештә файдаланырга өндәде.



*Влад Михневский фотолары*

• «Тарихи» очрашулар

# «Һәр телнең яшәргә хокукы бар»!

Материалны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

Татар тарихы... Мондый бәхәсле, фаҗигале тарих сирәк бу дөньяда. «Халыкның милли үзаңын бары тик бер юл белән генә күтәрергә буладыр. Ул да булса, аның тарихындагы барлык вакыйгаларны, дәверләрне ачыклау, халкыңның мескенлеген түгел, батырлыгын, кыюлыгын күрсәтү. Әгәр дә татарның милли үзаңы милләтенең тарихы биеклегенә күтәрелә алса, татар нинди шартларда да телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен югалтмас иде», – дип язды тарихчы И.Хуҗин. Татар тарихына караган кайбер мәгълүматлардан хәбәрдар булсак та, аны тулысынча беләбез, дип әйтү шикле тоелыр иде. Барлык шик-шөбһәләрне уку йортыбызда бик актив эшләп килә торган UNIVERSMOTPI.RU студентлар телевидениесендә бара торган «Искәндәр Гыйләҗев белән «тарихи» очрашулар тапшыруын карап юкка чыгара аласыз. Тапшыруны Ленар Мифтахов алып бара.

**– Дөньяда бер-ике кеше генә сөйләшә торган телләр бар. Менә шушы үзенчәлекле телләр үлеме бөтен бер этнос үлеменә китерә. Искәндәр Аязович, киләчәктә татар теле дә шундый телләр исемлегенә кермәсме?**

- Берәү дә телнең күпме яшисе калганын әйтә алмый. Тарих ул шундый нәрсә, теләсә кайсы мизгелдә борылып куярга мөмкин. Тел дә яңадан рухланып, үсеп китә ала. Әлбәттә, тел юкка чыгу куркынычы юк түгел. Әмма ситуацияне үзгәртеп, дөрес юнәлешкә борып җибәрү безнең кулда.

**- Татар милләте үзенең мөмкин булган үлемен лаеклы каршы аламы?**

- Бу уңайдан сөйләшергә, билгеле бер авырткан урыннарны, үсеш юлларын билгеләргә мөмкин. Чыннан да, кайбер яктан без тулаем тәэмин ителгән, кайбер яктан без агрессив, ә кайбер яктан хәтта куркытылган. Шулай да мин бүген татар милләте үлә дип әйтмәс идем. Россиядә татар милләтенә караганда да азрак тел йөртүчесе булган милләтләр бар. Әлегә хәтта алар да бетми. Тел үлеме – тел йөртүче милләт өчен генә түгел, бөтен кешелек җәмгыяте өчен һәлакәт. Телләр юкка чыгу мәсьәләсе – бүген халыкара проблема. Ник дигәндә, һәр тел – кешелекнең рухи культурасының бер өлеше. Һәр телнең яшәргә хокукы бар.

**- Урамда еш кына мондый күренешкә тап булырга туры килә: милләте белән татар булган кеше үз баласы белән нигәдер русча сөйләшә. Моннан чыгып, татар теле татарларның үзләренә кирәкме икән соң, дигән сорау туа.**

- Чыннан да, татарларның билгеле бер өлеше тел язмышына карата битараф. Һәм бу кешеләр яшәешкә практик яктан гына карый, чөнки алар Россиядә һәм Татарстанда татар теленең бик үк кирәкле булмавын аңлыйлар һәм рус телендә генә сөйләшүне кулайрак күрәләр. Бер яктан, бу чыннан да шулай. Әмма бөтен кеше дә андый түгел бит. Билгеле бер идеаллар белән яшәүчеләр дә бар. Кешеләрдә материаль, практик кызыксынулардан тыш, күңел дә бар. Ә тел ул – күңел көзгесе.

**- Телне югалтмас өчен безгә нишләргә кирәк?**

- Татар теле яңадан аякка бассын, үссен өчен, иң беренче чиратта, хакимиятнең аңлы сәясәте кирәк. Бу, бәлки, артык күп тапталган сүз булып яңгырыйдыр. Биредә Татарстанның гына түгел, ә күпмилләтле ил буларак, Росиянең дәүләт сәясәте дә күз алдында тотыла. Бүген гаиләгә, идеалистларга гына өметләнергә ярамый. Хәзер масштаблы дәүләт чаралары уздырылырга тиеш.




**- Дәүләт бит һәр мәсьәләгә прагматик яктан карарга ярата. Россия дәүләтенә татар телен саклау нигә кирәк?**

- Уңайлык дигән төшенчә бар. Иҗтимагый уңайлык, җәмгыятьтә уңайлы тормыш тойгысы... Миңа калса, дәүләт һәр гражданинын уңайлы тормыш белән тәэмин итәргә тиеш. Идеалда дәүләт шуның өчен кирәк тә бит. Әгәр, нindидер сәбәпләр аркасында, дәүләтнең нindидер бер өлешендә тормыш шартлары уңайлы түгел икән, дәүләт бу хакта уйланырга тиеш. Бу очракта эшне бик гади нәрсәдән башларга кирәктер. Югары урыннарны биләүчеләр, түрәләр татар телендә сөйләшеп, үрнәк күрсәтергә тиеш. Алар татар теле, тарихы, мәдәнияте, әдәбиятына карата чын-чынлап кызыксыну күрсәтәләр икән, халык та бу эшкә тартылачак.

***P.S.** Тапшыруның тулы вариантын **universmotri.ru/#** сылтамасы аша үтеп карый аласыз.*

• Сәнгать

# Тормыш турындагы җыр!

**Дания ФАТЫЙХОВА**


Влад Михневский фотосы

14 март көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Манзара» галереясендә РФнең Татарстандагы рәссамнар союзы әгъзасы, рәссамнар союзы идарәсе әгъзасы, сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты, укытучы Фәрит Рәшит улы Вәлиуллинның күргәзмәсе ачылды.

«Моңлы курай» исемле күргәзмә С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбенең сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре кандидаты, доцент **Р.Сәлахов** инициативасы белән, укытучы-рәссамның 55 яшьлек юбилеена багышлап үткәрелә.

Танылганрәссамныңиҗатҗимешләре белән танышырга теләүчеләр арасында уку йортыбыз укытучылары, студентлар һәм читтән килгән кунаклар да бар иде. Чараны Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының мәгариф эшләре буенча директор урынбасары **Рамил Мирзаһитов** ачып җибәрде. Ул Ф.Вәлиуллиннның эшчәнлеген югары бәяләде. Хәер, ул гына да түгел. Күпьеллык уңышлы фәнни-педагогик эшчәнлеге һәм яшь белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен, Фәрит Рәшит улы КФУ ректоры Илшат Гафуров исеменнән Мактау хаты белән бүләкләнде.

ТРның халык рәссамы Р.Вахитов юбилярның «Болгарларның исламны кабул итүе» монументаль мозаик панносын Татарстан сәнгатендә иң яхшылар рәтенә кертте. Аның фикеренчә, Ф.Вәлиуллин республикабызның монументаль сәнгате үсешендә аерым урын алып тора.

ТРның халык артисты, профессор Миңгол Галиев исә юбилярга үзенчәлекле бүләк ясады. Ул борынгы татар халык җырын башкарып, иҗади кичәнең милли колоритын тагын да арттырды. Рәссамның чарага килгән иҗатташ дуслары, хезмәттәшләре дә, аңа җылы сүзләр әйтеп, иҗат уңышлары теләделәр.

Күргәзмә ачылышына килгән һәркем рәссамның картиналарыннан ләззәтләнү хисе алгандыр, дип саныйм. Тарих сикәлтәләрен дөрес сиземләү, ата-бабаларыбызга, халыкка рәхмәт хисе һәм тормышны космик кабул итү – сәнгать турындагы әлеге күзаллаулар Фәрит Вәлиуллинның хезмәтләрендә чагылыш таба.

Күргәзмә 28 мартка кадәр Татарстан, 2 адресы буенча урнашкан «Манзара» галереясендә дәвам итәчәк.

• Ерактагы якын кардәшләр

18 март көнне Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты базасында эшләп килә торган Конфуций институтында кытай теле айлыгына багышланган сәнгатьле уку һәм каллиграфия конкурсы узды. Чарада КФУ, Яр Чаллы һәм Алабуга филиаллары студентлары, мәктәп укучылары катнашты. Конкурсантлар арасында Чебоксардан килгән кунаклар да бар иде.

# Кытай телен үз итәбез!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Бәйгене КФУ студентлары башлап җибәрде. Чыгышларның күбесе Кытай поэзиясенә багышланды. Дөрестән дә, Кытайлыларның иҗаты көннән-көн яңа үсеш ала. Бәйгенең максаты да нәкъ менә Кытай телен үстерү, үзләштерү, аның белән кызыксынучылар арасыннан иң оста сәнгатьле укучыларны билгеләү.

Чара төрле җыр-биюле чыгышлар белән үрелеп барды. Кытай телендә җырланган җырлар, сәхнәләштерелгән номерлар, биелгән биюләр, залдагы җылы атмосфера һәркемне көнчыгыш мәдәниятенә алып кереп китте.

Катнашучылар сөйләгән шигырьләрнең яки әсәләрнең тәрҗемәсе экранда яктыртылып барды. Экранга игътибар итмичә тыңлап утырсаң да, чыгыш ясаучының осталыгыннан, хис биреләешеннән ни турында сөйләгәнен азмы-күпме аңлап була. Ә тәрҗемәсен күзәтеп барган очракта, Кытай поэзиясенең никадәр үзенчәлекле, мәгънәле, йөрәккә үтеп кереп, кешенең аң дәрәҗәсен баета торган икәненә тагын да төшенәсең.

Мәсәлән, Чебоксардан килгән 10 сыйныф укучысы Юлия Ботинская чыгышының эчтәлеге белән уртаклашты: «Мин яшьлек, сафлык турында шигырь сөйләдем. Бу шигырьдә яшьлек кеше гомеренең кабатланмый торган гүзәл һәм шул ук вакытта иң җаваплы бер чоры икәне аңлатыла. Эчтәлеккә яшь үсенте яктылыкка, гүзәллеккә, биеккә омтылып үсә, күтәрелә; кеше дә камиллеккә омтылып яши: дус булырга, яратырга өйрәнә, дигән мәгънә салынган».


Влад Михневский фотосы

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының 5 курс студенты Айсинә Мансурова үзенчәлекле чыгышы белән аерылып торды. Ул да үз хисләрен яшерә алмыйча: «Көнчыгыш телләре белән мәктәптән үк кызыксына башладым. Башта төрек телен үзләштереп, шул өлкә буенча китәргә уйлап, КФУга укырга кердем. 2007 елда, Конфуций институты барлыкка килгәч, кытай телен өйрәнүгә зуррак игътибар бирдем һәм тулысынча үземне шул телгә багышладым».

Игътибарны диварларда эленгән төрле каллиграфия эшләре дә җәлеп итте. Анда язылганның мәгънәсе аңлашылмаса да, һәркайсы күз явын алырлык итеп эшләнгән.

Бәйге эчтәлекле, кызыклы, файдалы бәйрәм булып үтте. Һәр катнашучыга сертификат, ә җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр һәм мактау грамоталары тапшырылды. Чара чәй табыны артында тәмамланды. Әлеге матур чара күркәм традициягә әверелеп, киләчәктә дә дәвам итәр дип ышанам.

• Халәт

# Монда вакыт туктала!..

**Алсу НУРГАТИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Вакыт тар, диделәр! Интернет һәм яңа технологияләр заманы, диделәр! Бүген бу модада түгел, диделәр... Ләкин барыбер мине хат язышудан биздерә алмадылар.

Шулхәтле яратам мин хат язышырга. Әле башлангыч сыйныфта укыганда ук, бездән ерак яшәүче дәү әниемә, әнинең хаты белән бер конвертка салып, үз хатымны җибәрә идем. Тора-бара бу бер күркәм гадәткә әйләнде, дәү әни инде юк, ләкин хатлар язышу гадәте һаман сакланып калды.

Миңа калса, нинди генә яңа технологияләр заманы булмасын, берсе дә хат язышу ләззәтен алыштыра алмый. Интернет челтәре аша язышу башка, ә чын, кәгазь хатлар язышу ләззәте – ул бөтенләй икенче төрле. Уйлап кына карагыз, күз нурыңны түгеп, күңел җылысын салып, хат язып җибәрәсең. Ул, дистәләгән почта бүлекләре аша үтеп, газета арасына кысылып, хат ташучы кулыннан почта тартмасына килеп төшә. Ә конвертны кулга алгач, шатлану, читләрен ертып, хатның үзен укыганда дулкынланулар – әйтеп бетермәслек хисләр парады! Бер хатка күпме хис, күпме хатирәләр сыя бит!

Казанда инде өченче елымны укысам да, авылны, якыннарымны сагынуым сүлпәнәйсә дә, күңел күгемдә, болытлы төндәге йолдыз кебек, әле күренеп, әле куе томаннарга уралып «хат» дигән сүз янып ята. Сагындыра, барыбер сагындыра. Шуңа да авылда мәктәптә укып йөрүче сеңелем белән хат язышабыз. Сәер диярсез, айга бер булса да, кайтып торасың бит диярсез, тик хат язышу – хат язышу инде, ул хис-кичерешләрне берни белән дә алыштырып булмый. Гомумән, безнең хатлар – сандык кебек, аңа, тынгысыз хис-кичерешләр белән беррәттән, кечкенә чәй пакетигы кереп кунаклый, фоторәсем, ялкынланып карап кайткан театрдан билет һ.б. үз урынын таба. «Хатыңны укыгач, үзеңне күргән кебек булдым», – диярлек итеп, һәрбер хатны ихлас күңелдән язып, конвертны «баетып», шәһәр белән авыл арасында хатлар йөри. Тулай торак почтасыннан башкалар түләү квитанциясе һәм реклама листовкалары алганда, чыпчын, матурлап бизәлгән конвертлы хат алу – үзе бер куаныч! Алай гына да түгел, безнең эзләрдән атлап, яңа буын килә. Кайчан да булса безнең балаларыбыз, оныкларыбыз, бу юлны таптап, университет бусагаларын атлап керер, аудитория ишекләрен бәреп ачып белем туплар. Яңа технологияләр, интернет заманасы тагын да киң колач алыр, кәгазь китапларның, каләм-ручкаларның ни икәне онытылыр. Шул вакытта кайчандыр апа белән сеңел арасында йөргән хатларның кадере бермә-бер артыр, бу чын истәлек булыр.

Хатларны уку – чын хатирә! Чөнки монда вакыт туктала. Хат ул күңелнең фотосурәте!

***P.S.** Әгәр дә сезнең күңелегездә хатлар язышу теләге бар икән, үзегез кебек «сәер»ләрне табарга телисез икән, контакттагы «Күңел җебе» (**vk.com/kunelem**) төркеменә рәхим итегез. Үзегезгә ошаган анкетаны табасыз һәм хат язып саласыз! Үз анкетагызны да калдырырга онытмагыз!*

• Безнең канат

Инде берничә ел рәттән лицеебызда «Татар сәнгате» фестивале үткәрелә. Быел да без аны зурлап уздырдык.

# Безнең хәлләр яхшы!

**Әмир ЗАКИРОВ,**
Н.И.Лобачевский ис. лицейның
8 сыйныф укучысы

Фестивальнең максаты: халкыбызның милли-мәдәни традицияләрен үстерү һәм пропагандалау; милли әдәби, музыкаль, хореография сәнгатен таныту; безнең белемнәрне ныгыту.

Халык тарихын һәм хәзерге хәлен сәнгать аша өйрәнәләр. Безнең хәлнең яхшы икәнен шушы бәйрәмне карагач аңладым. Укучылар чарага бик җитди әзерләнгәннәр. Алып баручылар сөйләгән матур шигырьләр моңлы татар җырлары, дәртле биюләр белән үрелеп барды. Бу концерт номерларын татар дусларымның гына түгел, ә башка милләттән булган иптәшләремнең дә башкаруы фестивальгә тагын да ямь өстәде. Шулай итеп, без тагын бер кат лицеебызда үзара дус-тату яшәвебезне, бер гаиләдәге кебек бер-беребезне хөрмәт итүебезне дәлилләдек.



• Тәнгә - мунча, жанга - юк

# Тамагың тукмы, студент?

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Влад Михневский фотосы

Студентка, яхшы укыр өчен, нәрсә эшләргә кирәк? Бөтен парларга йөрергә, тырыш, максатчан булырга, дип җавап бирер күбегез. Әйе, бу фикер белән килешмичә мөмкин түгел, әмма белем алучы тук һәм сәламәт булмаса, яңа мәгълүматны үзләштерү кыен. Безнең университетта һәр факультетның диярлек үз буфетлары, ашханәләре бар. Беренче карашка, әлеге мәсьәлә уңай хәл ителгән кебек. Укы, яхшылап аша һәм янадан укы. Тик студентларны канәгатьләндерми торган нәрсәләр дә юк түгел икән.

**✦ Энҗе Сагирова, Фундаменталь медицина һәм биология институты:**

КФУның төп бинасында белем алам. Әмма биредә ашамыйм, ник дигәндә, урын бик аз һәм бәяләр югары. Әйбәтләп тамакны туйдырыр өчен, 200-300 сумга якын акча кирәк. Күбрәк университетның «физфагында» яки төп бина янында урнашкан «Coca cola» кибетендә тамак туйдырам.

**✦ Рияз Дәүләтшин, Физика институты:**

Без бәхетле кешеләр, тамагыбыз ачса, башка институтларга барасы юк, чөнки бездә менә дигән ашханә бар. Ул зур, меню да бик бай. 80-100 сумга аш, салат, чәй, берәр пешкән әйбер алып була. Ризыклар өйдәге кебек тәмле. Университет биргән талоннарны да монда кабул итәләр. Әмма бар нәрсә дә яхшы була алмый шул, безнең ашханәдә иң очсыз бәяләр булганга, монда гел зур чират. Кайвакыт парлар арасында керәсең, ә студентларның исәбесаны юк. Шәхсән минем 30-40 минут чиратта басып торганым бар. Ә тәнәфесләр озын түгел.

**✦ Алена Латыйпова, Икътисад һәм финанс институты:**

Университет бинасында урнашкан кафеда да, буфетта да ашаганым бар. Вакыт булганда, «Кольцо»га кереп тә тамак туйдырабыз. Гомумән алганда, мин кафедагы меню һәм ризыклардан канәгать. Бик тәмле пешерелгән, аңа өстәп, студентлар өчен даими рәвештә төрле акцияләр үткәрелә. 70-120 сумга менә дигән ашап була. Кафеда урын күп, көндезге аш вакытында чират була инде, әлбәттә, әмма ул тиз тарала.

**✦ Илнар Фәттахов, Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институты:**

Бинабызда ашханә булса да, еш кына беренче катта урнашкан буфетта ашарга туры килә. Ник дигәндә, безнең ашханәбездә ярты университет тамак туйдыра һәм, нәтиҗәдә, зур чират барлыкка килә. Ә тәнәфес кыска. Буфетта пешкән әйберләр һәм шоколадлар саталар. Минем фикеремчә, КФУда ашханәләр аз, шуңа күрә безнең бинада һәм «физфак»та гел бик зур чират.

**✦ Регина Шалаумова, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты:**

Эх, университеттагы ашханә турында сөйлисе дә килми. Дөресен генә әйткәндә, ул ашханә түгел, ә буфет. Беренчедән, ул бик кечкенә. Монда якынча 20-25 кешегә генә урын бар. Үзегез уйлап карагыз, бу бары тик бер төркем. Икенчедән, сау-сәламәт булыр өчен, өчпочмак, пицца, яки шоколад ашау гына җитми. Кайвакыт салатлар, боткалар да булгалый. Әмма аларны бик аз алып киләләр һәм төштән соң укучыларга ул җитми. Нәтиҗәдә, без төрле баллы әйберләр белән чәй эчәргә мәҗбүр. Алар да бит әле бик кыйммәт. Мәсәлән, кибеттә бик популяр шоколадны 25 сумга сатып алып булса, безнең буфетта ул 40-45 сум тора. Әйтерсең, без студентлар түгел, ә эшмәкәрләр.

**✦ Лилия Хасанова, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты:**

Без, күбесенчә, «Трали-Вали» кафесенда ашыйбыз. Әмма монда иң мөһим сүз – ул кафе. Ә, белгәнебезчә, кафеда ашханәгә караганда бәяләр зуррак. Биредә, бер ашаганда, 150-200 сум калдырасың. Үзегез уйлап карагыз, атнага без 5-6 көн укыйбыз. Нәтиҗәдә, ашханәдә 700 сумга якын акча калдырырга туры килә. Шуңа күрә кайбер төркемдәшләрем ризыкны өйдән пешереп алып киләләр яисә университет бинасы янында урнашкан кафеда пицца ашыйлар.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.